КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 август г.Казань № 699

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 сентябрь, 873 нче карары белән расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашуга бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашуга бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 сентябрь, 873 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 декабрь, 1281 нче; 2019 ел, 5 февраль, 70 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашуга бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау)

өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төрле чараларда катнашу өчен спорт командаларын, Татарстан Республикасы делегацияләрен командировкалау, визалар рәсмиләштерү, яшәү, туклану, тәүлеклеклек һәм чараларда катнашучыларны, бөтенроссия һәм халыкара иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен, техник белгечләрне командировкага җибәрү, алар чара регламенты буенча мәҗбүри булачак;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының әйдәп баручы спортчыларына ай саен шәхси стипендияләр түләү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин